Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 декабрь, 2023 ел № 300

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 18 маендагы 235 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 «Гражданнар мөрәҗәгатьләренең язма формасы» бүлегендә:

а) 4.1 өлештә «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «электрон почта адресы яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда шәхси кабинетның адресы (уникаль идентификаторы)» сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Бердәм порталда шәхси кабинет адресы);

б) 4.3 өлештә «яисә электрон почта адресын» сүзләрен «, электрон почта адресын яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4.7 өлештә «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләрен өстәргә;

г) 4.12 өлештә:

- икенче абзацта «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

- өченче абзацта «яисә Бердәм порталда шәхси кабинетлар адресларына» сүзләрен өстәргә.

1.2. «Гражданнарны шәхси кабул итү» 5 бүлегендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 5.5.1 өлеш өстәргә:

«5.5.1. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Бер үк вакытта чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 5.8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукка түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән очрашуга килгән гражданнар.

Бер үк вакытта беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукка берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 5.9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 5.10 өлештә «5.8 пунктында» сүзләрен «5.5.1 һәм 5.8 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга, «хокукка» сүзләреннән соң «чираттан тыш яисә» сүзләрен өстәргә.

1.3. «Мөрәҗәгатьне карау» 7 бүлегенең 7.4 өлешендә «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы — И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА